**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 7 июлендәге 2355 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2019 елның 12 июлендәге 2560 номерлы карары**
**белән расланган «Казансу елгасының иске үзәне һәм**
**Адмиралтейство бистәсе» территориясен планлаштыру**
**проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 12 июлендәге 2560 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 августындагы 2859 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 4624 номерлы, 2023 елның 2 маендагы 1240 номерлы һәм 2023 елның 29 декабрендәге 4411 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казансу елгасының иске үзәне һәм Адмиралтейство бистәсе» территориясен планлаштыру проектына, аерым өлешләрен кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 7 июлендәге
2355 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2019 елның 12 июлендәге 2560 номерлы карары белән
расланган «Казансу елгасының иске үзәне һәм
Адмиралтейство бистәсе» территориясен планлаштыру
проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә бирергә.

2. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.

3. Гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләрне күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 3 номерлы кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

4. Кызыл линияләр күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты сызымын, әлеге үзгәрешләрнең 5 номерлы кушымтасы нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген өстәп, әлеге үзгәрешләрнең 4 номерлы кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

5. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында, торак, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларының характеристикалары турында һәм мондый объектларның эшләве һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт,

социаль инфраструктура объектларының характеристикалары турында нигезләмәдә:

5.1. 3 пунктның 2 абзацында «220 792 кв.м» сүзләрен «273 492 кв.м» сүзләренә алмаштырырга;

5.2. 3 пунктның 1 таблицасында:

5.2.1. түбәндәге эчтәлекле 10 һәм 11 юллар өстәргә:

| **Кишәрлек номеры** | **Яңа торак төзелешен урнаштыру өчен кишәрлек адресы** | **Катлар саны** | **Фатирларның гомуми мәйданы (кв. м)** | **Тәэмин ителеш 1 кешегә 40 кв.м булганда халык саны (кеше)** |
|---|---|---|---|---|
| «10 | Адмиралтейство урамында 430 кв.м мәйданлы кертеп төзелгән торак булмаган биналар белән торак комплексы | 5 | 5 700 | 143 |
| 11 | К.Цеткин урамында 5100 кв.м мәйданлы кертеп төзелгән торак булмаган биналар белән торак комплексы | 7 | 47 000 | 1 175» |

5.2.2. «БАРЛЫГЫ» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Кишәрлек номеры** | **Яңа торак төзелешен урнаштыру өчен кишәрлек адресы** | **Катлар саны** | **Фатирларның гомуми мәйданы (кв.м)** | **Тәэмин ителеш 1 кешегә 30-40 кв.м булганда халык саны (кеше)** |
|---|---|---|---|---|
| «БАРЛЫГЫ | | | 273 492 | 10 687» |

5.3. 4 пунктның 2 таблицасында:

5.3.1. «Муниципаль мәктәпкәчә балалар учреждениеләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| **Билгеләнеше** | **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Егәрлеге** | **Саны** | **Җир кишәрлеге (га)** |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Двстр-1 | Мәктәпкәчә балалар учреждениесе (кертеп төзелгән) | Урыннар | 101 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән» |

5.3.2. «Торак-коммуналь хуҗалык учреждениеләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге юллар һәм искәрмәләр өстәргә:

| **Билгеләнеше** | **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Егәрлеге** | **Саны** | **Җир кишәрлеге (га)** |
|---|---|---|---|---|---|
| «Гвстр-1 | Җир асты паркингы | Машина урыны | - | 1 | Адмиралтейство урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| Гвстр-2 | Җир асты паркингы | Машина урыннары | 599*** | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Сөт кухняларының тарату пунктлары | Гомуми мәйданның кв.м | 50 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Даруханәләр | Гомуми мәйданның кв.м | 100 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Азык-төлек товарлары кибетләре | Гомуми мәйданның кв.м | 110 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | комплексында кертеп төзелгән |
| - | Азык-төлек булмаган товарлар кибетләре | Гомуми мәйданның кв.м | 47 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Химик ысул белән чистарту һәм кер юу пунктлары | Гомуми мәйданның кв.м | 100 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре, шул исәптән чәчтарашханәләр, ремонт белән шөгыльләнә торган остаханәләр, остаханәләрнең кабул итү пунктлары, прокат, фотохезмәтләр күрсәтү пунктлары, ателье | Гомуми мәйданның кв.м | 50 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Җәмәгать бәдрәфләре | Гомуми мәйданның кв.м | 50 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексында кертеп төзелгән |
| - | Торак-эксплуатацияләү оешмалары | Гомуми мәйданның кв.м | 50 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | комплексында кертеп төзелгән |

*** Күрсәткечләр кимегәндә (фатирларның гомуми мәйданы, торак булмаган билгеләнештәге биналарның гомуми мәйданы) парковка урыннары һәм башка инфраструктура объектлары ихтыяҗы күрсәткечләре, территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертмичә, Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары таләпләреннән чыгып, яңадан исәпләнә»;

5.3.3. «Инженерлык инфраструктурасы объектлары» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Билгеләнеше** | **Атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Егәрлеге** | **Саны** | **Җир кишәрлеге (га)** |
|---|---|---|---|---|---|
| «- | Канализация насос станциясе | Куб.м/тәүлек | 505 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексы янында |
| - | Локаль чистарту корылмалары | Литр/тәүлек | 30 | 1 | Клара Цеткин урамындагы торак комплексы янында» |

5.4. 5 пунктта:

5.4.1. түбәндәге эчтәлекле 5.6 пунктча өстәргә:

«5.6. Адмиралтейство урамындагы торак комплексы территориясендә транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикасы.

Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм әлеге комплекс составындагы кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен 68 машина урыны таләп ителә. Кирәкле машина урыннары санын җир кишәрлеге чикләрендә җир асты автомобиль тукталышларында һәм/яки яссылыкта оештыру күздә тотыла»;

5.4.2. түбәндәге эчтәлекле 5.7 пунктча өстәргә:

«5.7. К.Цеткин урамындагы торак комплексы территориясенә транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикасы.

К.Цеткин урамы урамындагы торак комплексы һәм әлеге комплекс составындагы кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен түбәндәге санда машина урыны күздә тотыла:

- җиңел автомобильләрне даими саклау өчен парковка урыннары – 413 машина урыны (шуларның 6 сы – электр энергиясен җыю станциясе булган урын);

- килүчеләр өчен җиңел автомобильләр кую урыннары – 84 машина урыны;

- торак булмаган биналар өчен җиңел автомобильләр саклау өчен парковка урыннары – 102 машина урыны.

Комплекс составында кимендә 599 машина урыны булган җир асты автомобиль кую урыннарын төзү күздә тотыла.

Машина урыннары яссылыкта да, җир асты паркингларында да (шул исәптән килүчеләр өчен машина кую урыннары) урнаштырылырга мөмкин»;

5.5. 6.1 пунктта:

5.5.1. 3 абзацта «6196,35 куб.м/тәүлек» сүзләрен «6807,71 куб.м/тәүлек» сүзләренә алмаштырырга;

5.5.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шул исәптән Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: су куллану – 50 куб.м/тәүлек. Адмиралтейство урамындагы Ø 800 мм лы суүткәргечкә тоташтыру башкарыла. Гомуми озынлыгы якынча 10 м булган челтәрләр салу күздә тотыла.

Шул исәптән К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: су куллану – 561,36 куб.м/тәүлек. Кече Мәскәү урамындагы Ø 800 мм лы суүткәргечкә тоташтыру башкарыла. Гомуми озынлыгы якынча 0,5 км булган челтәрләр салу күздә тотыла»;

5.6. 6.2 пунктта:

5.6.1. 2 абзацта «6196,35 куб.м/тәүлек» сүзләрен «6745,48 куб.м/тәүлек» сүзләренә алмаштырырга;

5.6.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шул исәптән Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: су чыгару – 45 куб.м/тәүлек. Адмиралтейство урамындагы Ø 600 мм лы канализация коллекторына тоташтыру башкарыла. Гомуми озынлыгы якынча 20 м булган челтәрләр салу күздә тотыла.

Шул исәптән К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: су чыгару – 504,126 куб.м/тәүлек. Җитештерүчәнлеге 505 куб.м/тәүлек булган канализация насос станциясе каралган. Несмелов урамындагы Ø 2000 мм лы канализация коллекторына тоташтыру башкарыла. Гомуми озынлыгы якынча 0,6 км булган хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләрен салу күздә тотыла»;

5.7. 6.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен ябык типтагы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү, аннары К.Цеткин урамындагы гамәлдәге челтәрләргә тоташтыру күздә тотыла. Үткәргеч торбалар озынлыгы якынча 250 м булачак.

К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар территориясеннән яңгыр һәм кар суларын читкә җибәрү өчен, яңгыр суларын локаль чистарту корылмаларыннан агынты суларны чистартып, яңгыр канализациясе системасын булдыру күздә тотыла. Алга таба К.Цеткин урамындагы Ø 1200 мм лы булган яңгыр канализациясе челтәрләренә тоташтыру каралган. Территория чикләрендә гомуми озынлыгы якынча 0,4 км булган яңгыр канализациясе челтәрләрен салу каралган»;

5.8. 6.4 пунктта:

5.8.1. 2 абзацта «54,949 МВт» сүзләрен «64,701 МВт» сүзләренә алмаштырырга;

5.8.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шул исәптән Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: җылылык белән тәэмин итү (җылылыкны гомуми куллану) – 0,8 Гкал/сәг. Җылылык челтәрләренә тоташтыру ТК-1 проектлаштыру территориясендә башкарыла. Ике торбалы җылылык челтәрләренең озынлыгы якынча 10 м тәшкил итәчәк.

Шул исәптән К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм торак булмаган биналар өчен: җылылык белән тәэмин итү (гомуми җылылык куллану) – 9,75 МВт. Туклану К.Цеткин урамы, 8/27 адресы буенча урнашкан котельныйдан, аны реконструкцияләү һәм аның гомуми егәрлеген арттыру шарты белән, шулай ук Казан шәһәр округының Генераль планы чаралары нигезендә гомумшәһәр әһәмиятендәге 1 класслы магистраль урамны гамәлгә ашыру вакытына кадәр каралган. Альтернатив туклану чыганагы проектлауның алдагы стадияләрендә билгеләнәчәк. Проектлана торган торак комплексын «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте җылылык челтәрләренә тоташтыру ноктасы К.Цеткин урамына таба салынган җылылык үткәргечтә каралган.

Ике торбадан төзелгән җылылык челтәрләренең озынлыгы якынча 0,5 км тәшкил итәчәк»;

5.9. 6.5 пунктта:

5.9.1. 2 абзацта «13520,04 кВт» сүзләрен «16093,45 кВт» сүзләренә алмаштырырга;

5.9.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шул исәптән Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: электр белән тәэмин итү (электр куллану [егәрлек]) – 315,0 кВт. Объектны Көнбатыш подстанциясенә, яңа блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенә тоташтыру каралган. 0,4 кВ көчәнешле электр челтәрләренең озынлыгы якынча 80 м тәшкил итәчәк.

Шул исәптән К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен: электр белән тәэмин итү (электр куллану [егәрлек]) – 2 258,41 кВт. 2 данә трансформатор подстанциясе төзү, аннары Көнбатыш подстанциясенә тоташтыру, шулай ук гамәлдәге бер трансформатор подстанциясен күчерү каралган. 0,4 кВ көчәнешле электр челтәрләренең озынлыгы якынча 0,7 км тәшкил итәчәк.

Шул исәптән К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар өчен проектлана торган территориядән гамәлдәге бер газ көйләү пунктын күчерү күздә тотыла»;

5.10. 6.6 пунктта түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«16:50:090104:13 кадастр номеры белән җир кишәрлеге территориясеннән проект буенча төзелеш зонасына эләккән газ белән тәэмин итү челтәрләрен чыгару һәм алга таба аларны күчереп салу күздә тотыла»;

5.11. 11 «Торак төзелеше территориясенең төзелеш параметрлары һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар» пунктын өстәргә:

**«Торак төзелеше һәм кертеп төзелгән торак булмаган биналар территориясенең төзелеш параметрлары**

3 таблица

| Кишәрлекнең тәртип номеры | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары исемнәре | Торак фондының гомуми мәйданы (кв.м) | Урнаштыру зоналары мәйданы (га) | Рөхсәт ителгән файдалану төре код | Торак фондының фактагы/ максималь тыгызлыгы (мең кв.м) | Урнаштыру зонасы төре | Максималь катлылык (кат) | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми мәйданы, | Объектлар турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | лары | | | | кв.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Катлар саны уртача булган торак йортлар төзелешен урнаштыру зонасы | 5 700 | 0,51 | 22.5, 2.7.1, 3.1.1, 34.1, 4.4, 4.6 | 11,3 /13,2 | 2 | 5 | 430 | Адмиралтейство урамындагы торак комплексы |
| 11 | Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы | 47 000 | 4,55 | 2.5, 2.7.1, 3.1.1, 3.5.1 | 10,3/15,0 | 2 | 7 | 5055 | К.Цеткин урамындагы торак комплексы» |

6. Түбәндәге эчтәлекле IX һәм X бүлекләрен өстәргә:

«IX. Адмиралтейство урамындагы торак комплексы һәм торак булмаган биналар өчен территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә.

Территорияне план буенча үстерү бер этапта карала. Транспорт һәм инженерлык инфраструктуралары объектларын төзү һәм файдалануга кертү этаплап планлаштырыла, аларны гамәлгә ашыру параллель рәвештә дә, капиталь төзелеш объектлары ихтыяҗларыннан чыгып, эзлекле рәвештә дә, шул исәптән финанслау бүлеп бирелгән һәм тиешле программаларга кертелгән очракта да мөмкин.

**Проектлана торган территория этапларын үзләштерү вакытлары**

4 таблица

| Этап | Торак билгеләнешендәге капиталь төзелеш объектлары | | | Инженерлык инфраструктурасы объектлары | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Катлар саны уртача булган торак йортлар төзелешен урнаштыру зонасы | | | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы | | |
| | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру | Төзелеш | Сүтү | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру | Төзелеш | Сүтү |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 4 кварталы | 2030 елның 3 кварталы | 2030 елның 2 кварталы | 2026 елның 4 кварталы | 2030 елның 3 кварталы | 2030 елның 2 кварталы |

X. К.Цеткин урамындагы торак комплексы һәм торак булмаган биналар өчен территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә.

Территорияне, район территориясен тулаем үстерү тәртибенә бәйләмичә, план буенча үстеререргә мөмкин.

Территорияне план буенча 1 (бер) этапта үстерү күздә тотыла.

Торак төзелеше объектларын төзү өлешендә территорияне үстерү һәм үзләштерү, кирәк булганда, торак төзелеше территориясенә туры килә торган тимер юллардан санитар ераклыкны киметү чараларын тәэмин иткән очракта башланырга мөмкин.

Торак төзелеше объектларын төзү өлешендә территорияне үстерү һәм үзләштерү Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә җир кишәрлеген «Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ)» территориаль зонасы чикләренә кертүне күздә тота торган үзгәрешләр кертү шарты белән башланырга мөмкин.

Мәгариф оешмалары объектларын, иҗтимагый-эшлекле, коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын, рекреация билгеләнештәге объектларны төзү, гамәлгә ашыру һәм файдалануга кертү параллель рәвештә һәм, капиталь төзелеш объектларына ихтыяҗдан чыгып, бер-бер артлы башкарылырга мөмкин.

Социаль, транспорт инфраструктуралары объектларын төзү тиешле объектларны төзү программаларына кертү шарты белән мөмкин һәм торак төзелеше чиратына бәйле түгел.

Казан шәһәр округының Генераль планы чаралары нигезендә гомумшәһәр әһәмиятендәге 1 класслы магистраль урамны гамәлгә ашырганчыга кадәр проектлана торган территорияне туклану үзәгеннән – К.Цеткин урамындагы 8/27 йорт адресы буенча урнашкан котельныйдан җылылык белән тәэмин итү каралган. Альтернатив туклану чыганагы (Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә тукланучы котельный объектына элгә торган гомумшәһәр әһәмиятендәге 1 класслы магистраль урамны гамәлгә ашыра башлау чараларыннан соң) проектлаштыруның алдагы стадияләрендә билгеләнәчәк.

**Проектлана торган территория этапларын үзләштерү вакытлары**

5 таблица

| Этап | Торак билгеләнешендәге капиталь төзелеш объектлары | | | Инженерлык инфраструктурасы объектлары | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Катлар саны уртача булган торак йортлар төзелешен урнаштыру зонасы | | | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы | | |
| | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру | Төзелеш | Сүтү | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру | Төзелеш | Сүтү |
| 1 | 2026 елның 4 кварталы | 2030 елның 3 кварталы | 2030 елның 2 кварталы | 2026 елның 4 кварталы | 2030 елның 3 кварталы | 2030 нчы елның 2нче кварталы» |

---

I.Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства

Приложение №1 к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Старое русло реки Казанки и Адмиралтейская слобода", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г. Казани от 12.07.2019 №2560




## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

### Границы, линии градостроительного регулирования

граница территорий, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории

граница проектируемого земельного участка

красная линия — действующая красная линия улично-дорожной сети

**10** — номер участка

**Гвстр-1** — подземный паркинг

### Зоны размещения

1 — порядковый номер зоны размещения

2 — вид зоны размещения объектов капитального строительства

0,51 — площадь зоны размещения (га)

2,5 — код вида разрешенного использования

5,70 — максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м)

5 — максимальная этажность (этаж)

зона размещения среднеэтажной жилой застройки (проект.)

### Объекты инженерной инфраструктуры

трансформаторная подстанция (ТП) (сущ.)

I.Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства

Приложение №2 к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Старое русло реки Казанки и Адмиралтейская слобода", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г. Казани от 12.07.2019 №2560




## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

### Границы, линии градостроительного регулирования

- граница территорий, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории
- граница элемента планировочной структуры (квартал)
- граница существующего земельного участка
- граница проектируемого земельного участка
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- 7 ○ условный номер характерных точек устанавливаемых красных линий
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- границы подземных паркингов
- **11** номер участка
- **ОЖ-1** жилой комплекс по ул. Клары Цеткин
- **Двстр-1** дестское дошкольное учреждение на 101 место (встроенное, ориент. местоположение)
- **Гвстр-2** Подземный паркинг

### Зоны размещения

- ① порядковый номер зоны размещения
- 1 вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 1,994 площадь зоны размещения (га)
- 2,6 код вида разрешенного использования
- 34,250 максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м)
- 20 максимальная этажность (этаж)
- 2 зона размещения среднеэтажной жилой застройки (проект.)
- 5 зона размещения объектов общественно-делового назначения (сущ.)
- 21 зона размещения объектов улично-дорожной сети (проект.)
- 4 зона размещения индивидуальной и блокированной жилой застройки (сущ.)
- 11 зона размещения объектов инженерной инфраструктуры (сущ.)
- 8 зона размещения объектов культурно-досугового назначения (сущ.)
- существующая сохраняемая застройка

### Объекты инженерной инфраструктуры

- трансформаторная подстанция (ТП, РТП) (встроенные, ориентир. местоположение, проект.)
- трансформаторная подстанция (ТП, РТП) (перенос, проект.)
- канализационная насосная станция хозяйственно-бытовой канализации (КНС) (ориентир. местоположение, проект.)
- очистные сооружения дождевой канализации (ЛОС) (проект.)
- пункт редуцирования газа (ПРГ) ( проект.)
- пункт редуцирования газа (ПРГ) (перенос, проект.)
- котельная (реконструкция)

III.Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием отменяемых красных линий

Приложение №3 к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Старое русло реки Казанки и Адмиралтейская слобода", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г. Казани от 12.07.2019 №2560




**УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ**

**Границы, линии градостроительного регулирования**

- граница территорий, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории
- граница элемента планировочной структуры (квартал)
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений

**11** номер участка

**ОЖ-1** жилой комплекс по ул. Клары Цеткин

**Двстр-1** дестское дошкольное учреждение на 101 место (встроенное, ориент. местоположение)

**Гвстр-2** Подземный паркинг

IV.Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий с поворотными точками

Приложение №4 к изменениям, вносимым в проект планировки территории "Старое русло реки Казанки и Адмиралтейская слобода", утвержденный постановлением Исполнительного комитета г. Казани от 12.07.2019 №2560




**УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ**

**Границы, линии градостроительного регулирования**

- граница территорий, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории
- граница элемента планировочной структуры (квартал)
- красная линия — устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- 7 — условный номер характерных точек устанавливаемых красных линий
- красная линия — действующая красная линия улично-дорожной сети
- красная линия — отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- граница отменяемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений

**11** — номер участка

**ОЖ-1** — жилой комплекс по ул. Клары Цеткин

**Двстр-1** — десткое дошкольное учреждение на 101 место (встроенное, ориент. местоположение)

**Гвстр-2** — Подземный паркинг